Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-4**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 23 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милек реестры турында” 2006 елның 4 октябрендәге X-3 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының “Муниципаль мөлкәт реестрларын җирле үзидарә органнары тарафыннан алып бару тәртибен раслау турында” 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы боерыгы чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 51 маддәсендәге 5 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 56 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милек реестры турында” 2006 елның 4 октябрендәге X-3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев